КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 декабрь г.Казань № 1147

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 март, 129 нчы; 2021 ел, 24 май, 365 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1076 нчы; 2022 ел, 5 декабрь, 1286 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 31 июль, 913 нче; 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче; 2024 ел, 30 май, 376 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында» сүзләрен «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның беренче абзацында «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында» сүзләрен «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктта:

өченче абзацка «(әлеге пунктның унынчы абзацында күрсәтелгән очрактан тыш)» сүзләрен өстәргә;

2.5 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала тапкан хатын-кыз тарафыннан баланың атасы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар

арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучылар, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләр категориясенә каравын раслый торган документ яки махсус хәрби операциядә катнашу аркасында баланың атасы һәлак булуын раслый торган документ тапшырылган очракта, балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын бирү гаиләнең җан башына туры килә торган уртача керемен исәпкә алмыйча гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин